КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1133

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, тасвирламасы һәм аларны күрсәтү күләме» таблицасындагы 4 бүлекнең 4.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.	Социаль-педагогик коррекцияләү, диагностика һәм консультация үткәрүне кертеп	Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының социаль дезадаптациясен диагностикалау, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки төзәтү шартларын билгеләү	чаралар комплексы	2	елга, социаль хезмәт күрсәтү чорына
		Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының шәхес үзенчәлекләрен һәм сыйфатын педагогик ысуллар белән максатчан үзгәртү; шәхеснең тулы кыйммәтле үсешен һәм эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан чыгып, үзенчәлекле ярдәм күрсәтү, үз-үзен тотышындагы кимчелекләрне төркемнәрдә яки индивидуаль рәвештә бетерү һәм профилактикалау (күрсәткечләр буенча); социаль хезмәтләр күрсәтүдән эшкә яраксыз файдаланучыларны һөнәри укыту, эшкә урнаштыру, эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу максатларында, һөнәри юнәлеш буенча мәгълүмат һәм консультация бирү; социаль хезмәтләр күрсәтүдән эшкә яраксыз файдаланучыларның һөнәри кызыксынуларын, омтылышларын, сәләтләрен ачыклау өчен һөнәри юнәлештә диагностика үткәрү; социаль хезмәтләр күрсәтүдән эшкә яраксыз файдаланучыларга бәйле мөнәсәбәттә укытуга һәм эшкә урнаштыруга	курслар	2	елга, социаль хезмәт күрсәтү чорына».

		карата булган карашларны төзәтү һәм мотивацияне үстерү			

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин